# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты турында

### I. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты (алга таба - Комитет дип аталачак) - Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон тарафыннан билгеләнгән чикләрдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тикшереп тору вәкаләтләрен тәэмин итүче органы ул.

<u>2 статья.</u> Комитетның оешу һәм эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон тарафыннан билгеләнә.

<u>3 статья.</u> Комитет хокукый зат була һәм аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы төшерелгән, үз исеме язылган мөһере була.

<u>4 статья.</u> Комитетны тоту өчен кирәкле акчалар Татарстан Республикасының республика бюджетыннан бүлеп бирелә. Ассигнованиеләр күләме ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

<u>5 статья.</u> Комитет үз эше турында кимендә елына бер тапкыр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушкан һәр эш буенча аерым-аерым хисап тота.

## П. Комитетның оешу һәм эшчәнлек тәртибе

6 статья. Комитет Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре чорына төзелә.

Комитет рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан сайлана.

Комитет рәисе урынбасары һәм Комитет әгъзалары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан сайлана.

7 статья. Комитет коллегиаль орган була.

Комитет утырышлары кирәк саен, әмма кварталга кимендә бер мәртәбә чакырыла. Утырышта Комитет составының кимендә өчтән икесе катнашса, утырыш тулы вәкаләткә ия була.

Комитет карарлары Комитет составының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм карар рәвешендә рәсмиләштерелә.

8 статья. Комитетка рәис җитәкчелек итә.

Рәис Комитет эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышларны чакыруны тәэмин итә, Комитет карамагына кертелүче материалларны әзерләүне оештыра, аның утырышларында рәислек итә, карарларга һәм күрсәтмәләргә имза сала, Комитетның аппарат хезмәткәрләрен эшкә кабул итә һәм эштән азат итә.

Комитет рәисе дәүләт органнарында Комитет исеменнән эш йөртә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты утырышларында катнашырга хаклы.

Комитет рәисе үз теләге буенча да, шулай ук үзенә йөкләнгән вазыйфаларны тиешенчә башкармаган өчен дә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә билгеләнгән урыннынан вакытыннан алда азат ителергә мөмкин.

Комитет рәисе урынбасары Комитет рәисе кушуы буенча аның кайбер вазыйфаларын үти һәм, Комитет рәисе эшендә булмаган очракта яисә рәиснең үз вазыйфаларын башкару мөмкинлеге булмаганда, рәисне алмаштыра.

9 статья. Комитет үзенең төзелешен һәм аппараты хакындагы нигезләмәне мөстәкыйль раслый.

Комитет аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, шулай ук аларның хезмәт итү шартлары әлеге Закон, "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законы, хезмәт турындагы законнар һәм башка норматив хокукый актлар тарафыннан билгеләнә.

Ш. Комитетның вазыйфалары һәм вәкаләтләре

10 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушуы буенча Комитет түбәндәгеләрне тикшереп тора:

1) Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен, үз вәкаләтләре чикләрендә;

2) Татарстан Республикасының республика бюджеты, дәүләтнең бюджеттан тыш һәм валюта фондлары үтәлешен;

3) дәүләтнең кредит һәм валюта ресурсларын куллану, дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләрен чыгару өлкәсендә Татарстан Республикасы Милли банкының, коммерция банкларының һәм башка кредит-финанс учреждениеләренең эшчәнлекләрен;

4) республика милкенә идарәне, дәүләт милкәтенә идарә итүдән (шул исәптән аны хосусыйлаштырудан, сатудан) алына торган акчаларның республика бюджетына кертелүен;

5) икътисадый һәм җәмгыяви үсеш буенча республиканың мөһим программалары үтәлешенең барышын.

Комитет Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушуы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагындагы башка мәсьәләләрне дә тикшереп тора.

Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын алу, күчерү яисә җәмәгать берләшмәләре, дәүләткә карамаган фондлар һәм дәүләткә карамаган башка коммерция оешмалары тарафыннан аларны куллану, республика милкен файдалану һәм аңа идарә итү буенча эшчәнлекләрен тикшереп тору да Комитет вәкаләтләренә керә.

11 статья. Комитет үз вазыйфаларын башкарганда түбәндәге хокукларга ия:

1) утырышларында түбәндәгеләрне тыңларга:

Татарстан Республикасының республика бюджеты, республика программалары, дәүләтнең бюджеттан тыш һәм валюта фондлары үтәлеше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әгъзаларын, районнарның һәм шәһәрләрнең хакимият башлыкларын;

Комитет карамагындагы барлык мәсьәләләр буенча халык депутатларының район, шәһәр һәм берләштерелгән Советларының рәисләрен, республика министрлыкларының, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарының җитәкчеләрен, шулай ук республика территориясендә урнашкан учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләрен;

Комитетның законнарны үтәгән килеш һәм үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларын дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан үтәү мәҗбүри. Әгәр Комитет тарафыннан башкасы каралмаган булса, күрелгән чаралар турында Комитетка бер ай эчендә хәбәр ителергә тиеш;

2) тикшерелүче предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеге турында барлык тиешле документларны соратып алырга.

Комитет үзе тикшерүче предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә ревизия уздыру турында, шулай ук экспертиза үткәрү турында кирәк чакта тиешле дәүләт органнарына һәм аларның урындагы затларына үтәлүе мәҗбүри булган йомышлар кушарга хаклы.

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Милли банкы, оешу-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм аларның урындагы затлары Комитет гарызнамәсе буенча аның белән килешенгән вакытларда кирәкле мәгълүматларны бирергә тиеш;

3) ачыкланган закон бозуларны билгеләнгән вакытларда төзәтү турында тикшерелә торган предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хакимиятләренә үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмәләрне үз вәкаләтләре чикләрендә бирергә.

Комитет ачыкланган закон бозулар турында һәм дәүләткә китерелгән зыян хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итә, ә административ яисә җинаять җаваплылыгына китерә

торган закон бозулар ачыкланганда, тиешле материалларны хокук саклау органнарына тапшыра;

4) тикшерүләрнең йомгаклау материалларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы халык депутатларына тапшырырга. Әлеге документларны карау һәм алар буенча кирәкле чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, тиешле министрлыкларга, дәүләт комитетларына, ведомстволарга һәм дәүләт идарәсенең башка органнарына җибәрергә;

5) законнарга, хокукый һәм физик затларның законлы мәнфәгатьләренә каршы килә торган актларның үтәлешен туктатып тору яисә юкка чыгару турында, шулай ук закон бозуларга юл куйган затларны биләгән эш урыннарыннан алу хакында һәм аларны законда каралганча җаваплылыкка тарту турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына һәм Министрлар кабинетына җибәрергә;

6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы белән мөрәҗәгать итәргә.

Таләп ителүче документларны бирүдән баш тарту яисә аларны яшереп калу, ялган мәгълүматлар бирү, Комитет карарларын күрәләтә торып үтәмәү, Комитет чакыруы буенча мәгълүм сәбәпләрсез килми калу гамәлдәге законнар нигезендә административ җаваплылыкка китерә. Комитет урындагы затларның эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре буенча аларга ышанычсызлык белдерү турындагы мәсьәләне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында кузгатырга хаклы.

<u>12 статья.</u> Комитет үз вазыйфаларын үтәгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре белән үзара килешеп эшли, уртак тикшерүләр үткәрә. Комитетның эш планы Татарстан Республикасы халык депутатларының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы даими комиссияләренең тәкъдимнәрен искә алып төзелә.

Тикшерүләр үткәргәндә, Комитет Татарстан Республикасы Президентының Контроль идарәсе, хакимиятнең һәм идарәнең җирле органнары белән үзара килешеп эшли, урындагы тикшерү органнарына ысулый ярдәм күрсәтә.

Ведомстволарның тикшереп тору органнары, прокуратура, эч-

55



ке эшләр, дәүләт иминлеге органнары, салым һәм таможня хезмәте, салым полициясе Комитетка тикшерү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда ярдәм итәргә тиеш.

Тикшерү эшчәнлеген башкарганда Комитет хокук саклау, финанс, салым һәм башка тикшереп тору һәм күзәтү органнары вәкилләрен, Татарстан Республикасы министрлыкларының, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарының белгечләрен, шулай ук килешү нигезендә дәүләтнеке булмаган аудиторлык хезмәтен, кайбер белгечләрне үзе үткәргән тикшерүләрдә катнашу өчен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә хаклы.

Тикшерүләр үткәргәндә Комитет Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының тикшереп торучы органнары белән үзара бәйләнештә тора.

13 статья. Үзенең хезмәт вазыйфаларын башкарганда Комитет рәисе һәм рәис урынбасары, Комитет әгъзалары түбәндәге хокукларга ия:

1) әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләт органнарына һәм, оешу-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга, банкларга, башка кредит-финанс учреждениеләренә тоткарлыксыз керергә;

2) тикшерү үткәргәндә таләп ителә торган барлык документлар белән танышырга, әмма коммерция серен саклау буенча йөкләмә алырга тиеш;

3) тикшерү үткәрүгә бәйләнешле мәсьәләләр буенча предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларыннан һәм башка хезмәткәрләреннән кирәкле белешмәләрне, телдән һәм язма аңлатмаларны алырга.

Комитет рәисенең һәм рәис урынбасарының, Комитет әгъзаларының хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйләнешле законлы таләпләре дәүләт органнары өчен, шулай ук, кемгә буйсынуларына һәм оешу-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар өчен мәҗбүри булып тора.

Тикшерелә торган объектларның җитәкчеләре Комитетның тикшерү үткәрүче вәкилләренә эшләү өчен тиешле шартлар тудырырга, аларга кирәкле бина, транспорт һәм элемтә чаралары бирергә, техник хезмәт күрсәтүне һәм эш башкару хезмәтен үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

Тикшерүләр һәм ревизияләр үткәрүгә каршылык күрсәтүче урындагы затлар Законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

Комитет рәисенең һәм рәис урынбасарының, Комитет әгъзаларының һәм Комитет аппараты хезмәткәрләренең билгеләнгән үрнәктәге хезмәт таныклыклары була.

14 статья. Комитет рәисе һәм рәис урынбасары, Комитет әгъзалары һәм аппарат хезмәткәрләре үткәрелүче тикшерүләрнең нәтиҗәләрен үзгәртеп күрсәткән өчен, дәүләт органнарына бирелүче һәм игълан ителүче мәгълүматларның дөреслеге өчен, дәүләт серен һәм закон тарафыннан саклanылучы башка төр серне хәбәр иткән өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 7 феврале
№415

3 parlamen.txt